## I.4. СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

Сүзлек 6 бүлек, 56 бүлекчәдән (лексиканы тематик классификацияләүнең гомуми планын форзацларда күрә аласыз), шулай ук күпсанлы вак тематик төркемчәләрдән тора, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең төре санлы индекс ярдәмендә күрсәтелә. Сүзлек номерланган 231 тематик төркемне үз эченә ала. Номерланган төркемнәр составындагы веграк (номерсыз) тематик төркемчәләр (алар 650 дән артык) бер-берсеннән горизонталь сызык белән аерылып тора.

Тематик төркемнәрдә сүзләр, аерым очракларда сүзтезмәләр тәкъдим ителгән. Алар сүзлек мәкаләләрендә дүрт өлештән (рус, татар, инглиз һәм төрек телләрендә) торган төп берәмлекләр буларак тасвирлана. Төп сүзләр өчен, ике ноктадан соң, сүзтезмәләр рәвешендә мисаллар, сирәк очракта – сүзне куллану үзенчәлекләрен күрсәтә торган җөмләләр китерелә, мәсәлән:

| | |
|---|---|
| передача: программа передач | тапшыру: тапшырулар программасы |
| пассажир: В трамвае много пассажиров | пассажир: Трамвайда пассажирлар күп |

Тематик төркемгә кертелгән сүзтезмәләргә, гадәттә, мисаллар китерелми, мәсәлән:

| | |
|---|---|
| часть тела | тән әгъзасы |
| сила воли | ихтыяр көче |

Аерым берәмлекләргә ике һәм күбрәк мисал китерелә; мондый очракларда мисаллар алдагы юлларда ике билгегә чигереп языла, мәсәлән:

| | |
|---|---|
| политика: | сәясәт: |
| внешняя ~ | тышкы ~ |
| международная ~ | халыкара ~ |

Мондый сүзтезмәләр белән бәйле ясалма сүзләр дә бер билгегә чигереп бирелә, мәсәлән:

| | |
|---|---|
| волосы, *ед.* волос: | чәчләр, *берл.* чәч: |
| тёмные волосы | коңгырт кара ~ |
| темноволосый: ~ человек | коңгырт кара чәчле: ~ кеше |
| чёрные волосы | кара ~ |
| черноволосый: ~ мальчик | кара чәчле: ~ малай |

Төп сүзләр сүзлектә, гадәттә, башлангыч формада тәкъдим ителә.

Исем сүз төркеменә караган сүзләр баш килештә берлек санда бирелә, мәсәлән:

| | |
|---|---|
| голова: <...> | баш: <...> |
| детство: <...> | балачак: <...> |

Әгәр сүзнең күплек саны үзенчәлекле формага ия булса, ул да өтердән соң *мн.* тамгасы белән китерелә, мәсәлән:

человек, *мн.* люди: <...>
ребёнок, *мн.* ребята, дети: <...>

Күплек санда гына кулланыла торган исемнәр баш килештә күплек сан формасында бирелә һәм янәшәдә *мн.* тамгасы куела, мәсәлән:

брюки *мн.*: <...>
весы *мн.*: <...>

Күпчелек очракта күплек санда кулланыла торган (әмма берлек сан формасы да булган) исемнәр башта күплек сан формасында бирелә, ә аннан соң *ед.* тамгасы белән берлек сан формасы китерелә, мәсәлән:

ботинки, *ед.* ботинок: <...>
усы, *ед.* ус: <...>

Сүз янәшәсендә *зд., мн.* тамгасы булу, сүзнең берлек сан формасы булса да, әлеге тематик төркемгә кергән мәгънәсенең күплек сан формасы белән белдерелүен күрсәтә, мәсәлән:

почки *зд. мн.*: <...>
обстоятельства *зд. мн.*: <...>

Сүзнең башлангыч формасы буенча исемнең җенес (род) категориясен билгеләү кыенлык тудырган очракларда (нечкәлек билгесенә тәмамлана торган исемнәрдә, төрләнми торган исемнәрдә), мәсәлән, род күрсәтелә:

такси *нескл. ср.*: <...>
вермишель *ж.*: <...>

Гомуми җенескә караган, ягъни ир-ат һәм хатын-кыз җенесендәге затларга карата кулланылырга мөмкин булган исемнәрдә, *м.* һәм *ж.* тамгасы куела, мәсәлән:

сирота *м.* и *ж.* <...>

Төрләнми торган исемнәрдә *нескл.* тамгасы куела, мәсәлән:

какао *нескл. ср.*: <...>
кафе *нескл. ср.*: <...>

Җыелма мәгънәле исемнәр янында *собир.* тамгасы бирелә, мәсәлән:

бельё *собир.*: <...>

Сыйфат сүз төркеменә караган сүзләр сүзлектә баш килештә берлек санда ир-ат җенесе (мужской род) формасында тәкъдим ителә, мәсәлән:

большой: <...>
самостоятельный: <...>

Аерым очракларда, әгәр тематик төркемгә сыйфат кыска форма белән белдерелә торган мәгънәдә керә икән, башта сыйфатның кыска формасы китерелә, ә аннары, *полн.ф.* тамгасыннан соң, тулы формасы бирелә, мәсәлән:

велик, *полн. ф.* великий: <...>
стар, *полн. ф.* старый: <...>

Рус телендә сыйфат сүз төркеменә караган сүз татар телендә исем сүз төркеменә караган сүз белән белдерелә, ә төп сүзгә тартым кушымчасы өстәлә икән, татар эквиваленты әлеге кушымчаның калын төре (ы) белән китерелә, аның алдына өч нокта куела, мәсәлән:

человеческий: ~ труд кеше ...ы: кеше хезмәте

Микъдар саннары баш килештә берлек санда бирелә, ә тәртип саны – баш килештә берлек санда ир-ат җенесе төрләнешендә (мужской род) китерелә, мәсәлән:

одиннадцать: <...>
пятидесятый: <...>

Сүзлектә фигыльләр билгесез формада тәкъдим ителә. Рус телендәге инфинитив татар теленә *-рга/-ргә* формалары белән тәрҗемә ителә, мәсәлән:

| | |
|---|---|
| жить *несов.*: ~ долго | яшәргә: озак ~ |

Төп өлештә, кагыйдә буларак, фигыльләрнең ике төре дә күрсәтелә: башта – тәмамланмаган төр (несовершенный вид), ә аннары өтердән соң – тәмамланган төр (совершенный вид), мәсәлән:

исполняться, исполниться: <...>
разбиваться, разбиться: <...>

Аерым очракларда «һәм» теркәгече ярдәмендә кушыла торган параллель формалар китерелә, мәсәлән:

гнуть, погнуть и согнуть: <...>

Бер тапкыр гына башкарыла торган хәрәкәт мәгънәсен аңлаткан фигыльләр янына *однокр.* тамгасы куела, мәсәлән:

стучать, постучать и *однокр.* стукнуть: <...>

Әгәр фигыль ике төрдә дә кулланыла икән, бу очракта аның бер формасы китерелә, аның янында *несов.* һәм *сов.* тамгасы куела, мәсәлән:

использовать *несов.* и *сов.*: <...>

Төп өлештә, әгәр аның бер формасы гына бар икән, бер фигыль бирелә. Бу очракта фигыль янына *несов.* яки *сов.* тамгасы куела, мәсәлән:

питаться *несов.*: <...>
пойти *сов.*: <...>

Сүз янәшәсендә *зд. несов.* яки *зд. сов.* тамгасы булу әлеге тематик төркемгә кергән сүзнең мәгънәсе күрсәтелгән формада булуын аңлата, мәсәлән:

утверждать *зд. несов.* <...>

Сүзлектә урынны экономияләү өчен, тильда (~) билгесе кулланыла. Тильда, мисалларда башлангыч формада кулланылган очракта, төп сүзне алыштыра (тильда бер һәм ике хәрефле сүзләрне алыштырмый), мәсәлән:

| | |
|---|---|
| ровесник: Он мой ~ | яшьтәш: Ул минем ~ |
| научный: ~ поиск | фәнни: ~ эзләнү |

Берничә төп сүз булган мәкаләдә тильда файдаланылса, бу аларның һәрберсенең күрсәтелгән мисалда кулланылырга мөмкин булуын аңлата, мәсәлән:

| | |
|---|---|
| замечать, заметить: ~ недостатки | күрергә, күреп алырга: кимчелекләрне ~ |

Татар, инглиз һәм төрек өлешләрендә бер-берсен алыштыра ала торган сүзләр түгәрәк җәяләрдә китерелә, мәсәлән:

| | |
|---|---|
| звучать *несов.*: Вдали звучат голоса | яңгырарга, ишетелергә: Еракта тавышлар яңгырый (ишетелә) |

Сүзләрнең, сүзтезмәләрнең һәм җөмләләрнең факультатив өлешләре квадрат җәяләрдә бирелә, мәсәлән:

второе [блюдо]: Я возьму только второе

писательница: талантливая ~ [female] writer: talented ~

Төп берәмлек вариантлары (төрле язылышы булырга мөмкин булган һ.б. очракларда) авыш сызык аша бирелә, мәсәлән:

нуль / ноль: На улице ~ градусов нуль / ноль: Тышта ~ градус

медицинский осмотр / *сокр.* медосмотр

Аерым очракларда, зур күләмле материалны кабатламас өчен, башка тематик төркемнәргә сылтамалар кулланыла, мәсәлән:

одиннадцать: ~ умножить на пять унбер: унберне бишкә тапкырларга
*См. ткж.* ● 223 *Кара шулай ук* ● 223

Тематик сүзлекнең өске өлешендә әлеге битләрдә урнаштырылган бүлекчә һәм төркемнәрнең саннары күрсәтелгән: башта бүлекчә саны, аннары ● тамгасыннан соң – тематик төркем номеры бирелә, мәсәлән: 1.6. ● 18.